КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 июль г.Казань № 543

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә киңлек мәгълүматлары инфраструктурасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 26 март, 239 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә киңлек мәгълүматлары инфраструктурасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 ел, 26 март, 239 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә киңлек мәгълүматлары инфраструктурасы турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Бердәм электрон картографик нигез мәгълүматлары составына карата таләпләр һәм аларны әледән-әле яңартып торуга карата таләпләр билгеләү турында» 2016 ел, 27 декабрь, 853 нче боерыгы»;

5.1 пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә

үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктның җиденче абзацында «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасындагы» сүзләренә алмаштырырга;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Киңлек мәгълүматлары инфраструктурасын булдыру һәм үстерү чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән расланган «2014 – 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин